КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 18 июнь г.Казань № 502

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә хуҗалары булмаган хайваннар белән мөгаләмә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2019 ел, 30 декабрь, 1275 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә хуҗалары булмаган хайваннар белән мөгаләмә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә хуҗалары булмаган хайваннар белән мөгаләмә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2019 ел, 30 декабрь, 1275 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә хуҗалары булмаган хайваннар белән мөгаләмә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.24 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.24. Хайваннар өчен приютларда яши торган хуҗасыз хайваннарны үтерү тыела, хайванның ветеринария өлкәсендә белгеч тарафыннан дөрес билгеләнгән, авыр дәваланмый торган авыруы булгандаяшәргә сәләтсез яки хайван гомере белән туры килми торган кискен җәрәхәт нәтиҗәсендә хайваннарның физик газапларын туктату зарурилыгы очракларыннан тыш һәм тиешле процедура ветеринария

өлкәсендә белгеч тарафыннан тиз арада һәм авыртуларсыз үлемне гарантияләүче гуманлы ысуллар белән башкарылырга тиеш.»;

3.25 пунктны үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин